Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

17 июнь 2021 ел № 35

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре бюджетына чиста табышның бер өлешен күчерү тәртибе турында нигезләмә хакында» 2014 елның 3 июлендәге 137 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре бюджетына чиста табышның бер өлешен күчерү тәртибе турында нигезләмә хакында» 2014 елның 3 июлендәге 137 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 94 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. муниципаль унитар предприятиеләрнең Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре бюджетына күчерү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымтада салымнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләгәннән соң калган табыш өлешеннән "Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре бюджетына күчерелергә тиешле чиста табыш чараларын исәпләү» не түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № п/п | Күрсәткеч | Күләме, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Хисап чорының чиста табышы (зыян) (финанс нәтиҗәләре турында 2400 хисапның юлы), Россия Федерациясе Салым кодексының 251 статьясын исәпкә алып | |
| 2 | Билгеләнгән түләү ставкасы | 1% |
| 3 | Исәпләнгән түләү суммасы (стр.1хстр.2) | |

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов